Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

12.02.2021 Менделеевск ш. № 85

Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук Менделеевск шәһәре территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясе Беркетмәсенең 24, 25 пунктларын гамәлгә ашыру максатында 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елның 23 августыннан 488 нче номерлы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук Менделеевск шәһәре территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук Менделеевск шәһәре территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турындагы Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.12 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Конкурста катнашучыларның Россия Федерациясе бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмаска тиеш.»

1.2. Нигезләмәнең 5.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча белән тулыландырырга:

«4) Россия Федерациясе бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булу.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Абдуллин